# IV ЧАКЫРЫЛЫШ ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МӨСЛИМ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ СОВЕТЫНЫҢ III СЕССИЯСЕ

## К А Р А Р №22

Мөслим «14» декабрь 2020 ел

**«Мөслим муниципаль районының махсуслаштырылган торак фондыннан торак урыннары бирү тәртибе турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2013 елның 25 апрелендәге 139 номерлы Мөслим муниципаль районы Советы карарына үзгәрешләр кертү турында**

Россия Федерациясе Торак кодексының 14 статьясы, «Татарстан Республикасы махсуслаштырылган торак фондының торак урыннарын бирү тәртибе турында» 2007елның 20 сентябрендәге 475 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары, «Россия Федерациясе мәҗбүри үтәтү органнарында хезмәт итү һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2019 елның 01 октябрендәге 328-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә Мөслим муниципаль районы Советы **КАРАР БИРДЕ:**

1. Мөслим муниципаль районының махсуслаштырылган торак фондына торак урыннары бирү тәртибе турында нигезләмәнең 3 бүлеген түбәндәге эчтәлекле 3.7 пункты белән тулыландырырга:

Социаль наем килешүләре буенча торак урын яллаучылар яисә социаль наем килешүе буенча торак урын яллаучының гаилә әгъзалары яисә торак урын милекчесенең гаилә әгъзалары һәм торак урыннарына мохтаҗ буларак исәптә торучы торак урын милекчеләре яисә торак урын милекчесенең гаилә әгъзалары булып тормаган затлар башка торак урыннар бирмичә хезмәт урыныннан бирелә торган торак урыннарыннан һәм тулай торaклардагы торак урыннарыннан чыгарыла алмыйлар:

1) хәрби хезмәткәрләрнең, Россия Федерациясе эчке эшләр органнары, федераль иминлек хезмәте органнары, таможня органнары, дәүләт янгынга каршы хезмәт органнары, наркотик чаралар һәм психотроп матдәләр әйләнешен контрольдә тоту органнары, җинаять-җәза үтәтү системасы учреждениеләре һәм органнары, Россия Федерациясе мәҗбүри үтәтү органнары вазифаи затларың, хезмәткәрләренең, хәрби хезмәт вазифаларын яисә хезмәт вазифаларын башкарганда һәлак булган (вафат булган) яисә хәбәрсез югалган затларның гаиләләре әгъзалары;

2) картлык буенча пенсионерлар;

3) хезмәт урыныннан торак урыны яки тулай торакта торак урыны бирелгән вафат булган хезмәткәрнең гаилә әгъзалары;

4) эш бирүче гаебе белән хезмәттә имгәнү аркасында инвалидлык алган I яки II төркем инвалидлар, хезмәт бурычларын үтәүгә бәйле рәвештә һөнәри авыру нәтиҗәсендә инвалидлык алган I яки II төркем инвалидлар, хәрби хезмәт бурычларын үтәгәндә яки хәрби хезмәт бурычларын үтәүгә бәйле авыру нәтиҗәсендә алынган яралану, контузия яки имгәнү аркасында I яки II төркем инвалидка әйләнгән хәрби хезмәткәрләр исәбеннән булган инвалидлар, инвалид балалары, балачактан инвалид гаилә әгъзалары булган гаиләләр.

2. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

Мөслим муниципаль районы Башлыгы
Мөслим муниципаль районы Советы Рәисе Р.Х. Муллин